# Сабантуй

Сабантуйлар килә гөрли-гөрли
Авылым халкы төшә мәйданга.
Дус-туганнар бер-берләрен таба,
Шул күрешеп алу үзе бер дәва

Сабантуе - хезмәт бәйрәме ул,
Җырлы-биюле милли бер гадәт.
Җилдән тизрәк атлар чабып уза,
Көрәш бара..Батырларга зур куәт.

Җәйге көндә мәйдан уртасында,
Бар халыкны җыя бер бәйрәм
Гореф-гадәтләрне саклап барган өчен,
Татар халкым, сиңа зур рәхмәт!

Бәзәкәмдә сабантуйлар гөрли,
Күкләр булсын безнең гел тыныч.
Очрашулар, бәхет, елмаюлар,
Килеп торсын һәркөн куаныч

*Раилә Гирфанова, 2025 ел, июнь*